Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының

Колшәрип авыл Советы

КАРАР

14 декабрь 2022 ел № 51

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Колшәрип авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге тарафынна шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең вәкаләтләре өлешен гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәрне кабул итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Әлмәт муниципаль районының «Колшәрип авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, «Әлмәт муниципаль районы территориясендә урнашкан җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру (кабул итү) турында Әлмәт муниципаль районының җирле үзидарә органнары белән килешүләр төзү тәртибе хакында» Әлмәт муниципаль районының 2015 елның 6 маендагы 468 номерлы карары нигезендә

Колшәрип авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Колшәрип авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге тарафыннан шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең вәкаләтләре өлешен гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәрне кабул итәргә.

2. Әлмәт муниципаль районының Колшәрип авыл Советына Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Әлмәт муниципаль районы бюджетыннан Колшәрип авыл җирлеге бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән вәкаләтләр өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру турында Әлмәт муниципаль районы Советы белән килешү төзергә.

3. Татарстан Республикасы Әлмә тмуниципаль районының Колшәрип авыл Советы карарын гамәлдән чыгарырга:

«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Колшәрип авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге тарафыннан шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итүбуенча «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең вәкаләтләре өлешен гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәр кабул итү турында» 2021 елның «14» октябрендәге 23 номерлы;

«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Колшәрип авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге тарафыннан шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең вәкаләтләре өлешен гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәр кабул итү турында» 2021 елның «21» декабрендәге 28 номерлы;

«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Колшәрип авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге тарафыннан шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең вәкаләтләре өлешен гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәр кабул итү турында» Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл Советының 2021 елның «14» октябрендәге 23 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның «19» гыйнварындагы 32 номерлы;

4. Әлеге карарны Колшәрип авылы, Тукай урамы, 50 йорт торак пунктлар территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә), «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

6.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Колшәрип
авыл җирлеге башлыгы А.Ф. Кәшәфетдинов